КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 6 март г.Казань № 210

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органының үзәк аппараты структурасы стандартын раслау турында» 2008 ел, 7 апрель, 207 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2009 ел, 13 май, 313 нче; 2021 ел, 2 март, 109 нчы; 2021 ел, 1 апрель, 202 нче, 2021 ел, 27 май, 379 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органының үзәк аппараты структурасы стандартына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3 пунктта:

дүртенче абзацка татар текстында «саны» сүзенә кадәр «хезмәткәрләр» сүзен өстәргә;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Әлеге пунктның икенче - дүртенче абзацларында билгеләнгән күрсәткечләрнең берсен дәүләт хакимияте башкарма органының үзәк аппараты хезмәткәрләренең гомуми штат санына карата бер берәмлекнең мөнәсәбәте буларак билгеләнә торган мәгънәгә арттырганда хезмәткәрләр штатында 30 берәмлеккә кадәр булган дәүләт хакимиятенең башкарма органы өчен күрсәткечне Стандартка туры килә дип санарга рөхсәт ителә»;

5 пунктта «Штат саны булганда» сүзләрен «Хезмәткәрләрнең гомуми штат саны булганда» сүзләренә алмаштырырга;

7 пунктның өченче абзацында «саны» сүзеннән соң «үзәк аппарат хезмәткәрләре» сүзләрен өстәргә;

10 пунктның икенче һәм өченче абзацларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Дәүләт хакимияте башкарма органында үзәк аппарат хезмәткәрләренең гоуми штат саны 40 берәмлеккә кадәр (40 берәмлекне кертеп) булганда департамент хезмәткәрләренең штат саны кимендә 14 берәмлек тәшкил итә. Департаментта, әгәр дә департамент хезмәткәрләренең  штат саны 14 берәмлектән (департамент җитәкчесен кертеп) артык булса, департамент җитәкчесе урынбасары вазыйфасы каралырга мөмкин. Департамент җитәкчесенең икенче урынбасары вазыйфасы департамент хезмәткәрләренең штат саны 28 берәмлек һәм аннан күбрәк (департамент җитәкчесен кертеп) булганда кертелергә мөмкин.

Дәүләт хакимияте башкарма органында үзәк аппарат хезмәткәрләренең гомуми штат саны 40 берәмлектән артык булганда, департамент хезмәткәрләренең штат саны кимендә 16 берәмлек тәшкил итә. Департаментта, әгәр дә департамент хезмәткәрләренең штат саны 16 берәмлектән (департамент җитәкчесен кертеп) артык булса, департамент җитәкчесе урынбасары вазыйфасы каралырга мөмкин. Департамент җитәкчесенең икенче урынбасары вазыйфасы департамент хезмәткәрләренең штат саны 32 берәмлек һәм аннан күбрәк (департамент җитәкчесен кертеп) булганда кертелергә мөмкин.»;

11 пунктта:

икенче абзацта «штат саны» сүзләрен «хезмәткәрләрнең гомуми штат саны» сүзләренә алмаштырырга;

өченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Дәүләт хакимияте башкарма органында үзәк аппарат хезмәткәрләренең гомуми  штат саны 40 берәмлектән артык булганда идарә хезмәткәрләренең штат саны кимендә тугыз берәмлек тәшкил итә. Идарәдә, әгәр дә идарә хезмәткәрләренең штат саны тугыз берәмлектән артык (идарә башлыгын кертеп) тәшкил итсә, идарә башлыгы урынбасары вазыйфасы каралырга мөмкин. Идарә башлыгының икенче урынбасары вазыйфасы идарә хезмәткәрләренең штат саны 18 берәмлек һәм аннан күбрәк (идарә башлыгын кертеп) булганда кертелергә мөмкин.»;

12 пунктта:

икенче абзацта «штат саны» сүзләрен «хезмәткәрләрнең гомуми штат саны» сүзләренә алмаштырырга, «саны» сүзенә кадәр «хезмәткәрләр» сүзләрен өстәргә, «сектор башлыгы» сүзләрен «сектор мөдире» сүзләренә алмаштырырга;

өченче абзацта «штат саны» сүзләрен «хезмәткәрләрнең гомуми штат саны» сүзләренә алмаштырырга, «саны» сүзенә кадәр «хезмәткәрләр» сүзен өстәргә, «сектор башлыгы» сүзләрен «сектор мөдире» сүзләренә алмаштырырга;

бишенче абзацта «штат саны» сүзләрен «хезмәткәрләрнең штат саны» сүзләренә алмаштырырга;

13 пунктта «штат саны» сүзләрен «хезмәткәрләрнең штат саны» сүзләренә алмаштырырга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре тарафыннан дәүләт эшләрен башкаруга (хезмәтләр күрсәтүгә) норматив чыгымнарны хисаплап чыгару тәртибен һәм Дәүләт эшләрен башкаручы Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләренең норматив санын хисаплап чыгару методикасын раслау турында» 2013 ел, 1 июнь, 376 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 ел, 17 июль, 500 нче; 2018 ел, 14 август, 666 нчы; 2021 ел, 2 март,

109 нчы, 2021 ел, 14 июль, 569 нчы карарлары нигезендә кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасының дәүләт учреждениеләре тарафыннан дәүләт эшләрен (хезмәтләрен) башкаруга (күрсәтүгә) чыгымнар нормативларын хисаплап чыгару тәртибенең 2.6 пунктының тугызынчы абзацында «0,4» саннарын «4» санына алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Дәүләт эшләрен башкаручы Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләренең норматив санын хисаплап чыгару методикасында:

2 нче таблицаның «Керүчеләрнең (гардероб булган музейлар, китапханәләр өчен) өске кием һәм башка вак шәхси әйберләрен кабул итеп, саклау һәм бирү» юлын түбәндәге редакциядә бирергә:

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| «Керүчеләрнең өске кием һәм башка вак әйберләрен кабул итү, саклау һәм бирү (гардероб булган музейлар, китапханәләр өчен) | хезмәткәрләр саны | 200 элмәккә 1 | | +»; |

5.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.2. Дәүләт учреждениесе хезмәткәрләренең штат санын исәпләп чыгарганда дәүләт учреждениесе җитәкчесе һәм аның урынбасарлары исәпкә алына.

Гамәлгә куючы карары буенча дәүләт учреждениесенең оештыру структурасы, законнарда каралган очраклардан тыш, дәүләт учреждениесе җитәкчесе яисә аны гамәлгә куючы боерыгы белән төзелергә һәм расланырга мөмкин.

Дәүләт учреждениесенең штат расписаниесе бердәм булырга тиеш.

Дәүләт учреждениесе җитәкчесенең вазыйфасы «директор» дип атала. Дәүләт учреждениесе җитәкчесенең иң күбе бер ярдәмчесе булырга мөмкин. Оештыру структурасында һәм штат расписаниесендә киңәшче вазыйфасы булу рөхсәт ителми.

Дәүләт учреждениесе җитәкчесе урынбасарларының саны дәүләт учреждениесен гамәлгә куючы карары белән раслана.

Дәүләт учреждениесе җитәкчеләре һәм аларның урынбасарлары, структур бүлекчәләр җитәкчеләре һәм аларның урынбасарлары саны хезмәткәрләрнең штат санының 30 процентыннан артмаска тиеш.

Җитәкчеләрнең һәм аларның урынбасарларының, структур бүлекчәләр җитәкчеләренең һәм аларның урынбасарларының саны буенча күрсәткечне арттырганда, хезмәткәрләр штатында булган дәүләт учреждениесе өчен дәүләт учреждениесе хезмәткәрләренең бер берәмлегенең дәүләт учреждениесе хезмәткәрләренең штат санына карата мөнәсәбәте буларак билгеләнә торган мәгънәгә әлеге пунктның алтынчы абзацында билгеләнгән тиешле таләпне санарга рөхсәт ителә.

Дәүләт учреждениесенең оештыру структурасына дәүләт учреждениесе эшчәнлегенең төп юнәлешләре буенча төзелгән департаментлар, идарәләр, бүлекләр, секторлар формасында, шулай ук дәүләт учреждениесе эшчәнлеген оештыру, матди-техник һәм башка тәэмин итү максатларында структур бүлекчәләр керергә мөмкин.

Департамент составында кимендә өч структур бүлекчә булырга тиеш, аның составында кимендә бер идарә һәм бер бүлек булуы мәҗбүри булып тора.

Дәүләт учреждениесе хезмәткәрләренең штат саны 30 берәмлеккә кадәр:

дәүләт учреждениесе җитәкчесенең урынбасары буйсынуында башка структур бүлекчәләр составына керми торган кимендә ике структур бүлекчә булырга тиеш, аларда кимендә алты хезмәткәр штатта булганда;

бүлекләрнең штат саны хезмәткәрләре  кимендә дүрт берәмлек булырга тиеш.

Дәүләт учреждениесе хезмәткәрләренең штат саны 31 берәмлектән һәм аннан да күбрәк булганда:

дәүләт учреждениесе җитәкчесенең урынбасары буйсынуында башка структур бүлекчәләр составына керми торган кимендә өч структур бүлекчә булырга тиеш, аларда кимендә 10 хезмәткәр штатта булганда;

идарә структурасына хезмәткәрләрнең  штат саны кимендә 13 берәмлек булган кимендә өч структур бүлекчә керергә тиеш. Идарәдә, әгәр дә идарә хезмәткәрләренең штат саны 13 берәмлектән артык (идарә башлыгын кертеп) тәшкил итсә, идарә башлыгы урынбасары вазыйфасы каралырга мөмкин. Идарә башлыгының икенче урынбасары вазыйфасы  хезмәткәрләрнең штат саны 26 берәмлек һәм аннан күбрәк (башлыкнын кертеп) булганда кертелергә мөмкин;

бүлекләрнең штат саны хезмәткәрләре  кимендә дүрт берәмлек булырга тиеш.

Хокукый, кадрлар белән тәэмин итүне гамәлгә ашыручы бүлекләр формасында, мобилизация эше буенча структур бүлекчәләрдә штат хезмәткәрләре саны кимендә өч берәмлек булырга тиеш. Әлеге бүлекчәләрдә хезмәткәрләр штат саны ике берәмлек булган очракта, алар сектор формасында оештырыла.

Бүлек башлыгы урынбасары вазыйфасы бүлек хезмәткәрләренең  штат саны кимендә алты берәмлек (шул исәптән бүлек башлыгын кертеп) булганда кертелә.

Бүлек башлыгының икенче урынбасары вазыйфасы бүлек хезмәткәрләренең штат саны кимендә 12 берәмлек (шул исәптән бүлек башлыгын кертеп) булганда кертелә.

Секторларда хезмәткәрләрнең штат саны кимендә ике берәмлек булырга яисә департаментлар, идарәләр, бүлекләр составына керергә, яисә аның мөстәкыйль структур бүлекчәләре булырга мөмкин. Секторга сектор башлыгы  җитәкчелек итә.

Дәүләт учреждениесенең оештыру структурасында хокукый, кадрлар белән тәэмин итү, мобилизация эше буенча аерым белгечләр, шулай ук матбугат сәркатибе сыйфатында белгеч булу рөхсәт ителә.

Хокукый, кадрлар белән тәэмин итүне, бухгалтерлык исәбен, мобилизация эшен алып баруны гамәлгә ашыручы структур бүлекчәләр (бүлекләр, секторлар, аерым белгечләр) һәм матбугат сәркатибе дәүләт учреждениесе җитәкчесенең турыдан-туры буйсынуында булырга тиеш.

Дәүләт учреждениесенең штат расписаниесендә дәүләт учреждениесен матди, техник һәм оештыру ягыннан тәэмин итү мәсьәләләренә җавап бирүче эшләр идарәчесе вазыйфасы булу рөхсәт ителә. Эшләр идарәчесенең хезмәт өчен түләү дәрәҗәсе дәүләт учреждениесенең расланган хезмәт өчен түләү фонды чикләрендә идарә башлыгының хезмәт өчен түләү дәрәҗәсенә туры килә. Аның тарафыннан җавап бирелә торган структур бүлекчәләр саны дәүләт учреждениесенең оештыру структурасы белән билгеләнә.

Дәүләт учреждениесенең хезмәт күрсәтүче персоналы вазыйфалары («машина йөртүче» вазыйфасын кертеп) (балансча булган яки арендага алына торган хезмәт урынында кулланылган автотранспорт булганда) дәүләт учреждениесенең штат расписаниесенә кертелә, яки әлеге персонал функцияләре законнар нигезендә төзелгән шартнамә нигезендә, дәүләт учреждениесендә хезмәт күрсәтүче персоналының штат санын алга таба кыскартып, башка оешмага тапшырыла. Хезмәт күрсәтүче персоналның норматив штат саны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнгән нормативлардан чыгып билгеләнә.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы Р.К.Нигъмәтуллин